**Тема**: Кеше- җирнең гүзәл бизәге.

**Максат:**

1.Укучыларны “Кеше- җирнең гүзәл бизәге” дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп тормышта эти- әниләрен, өлкәннәрне хөрмәт итәргә йөрәтү.

2. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.

3. Балаларга үз- үзеңне тәрбияләү- Аллаһның ризалыгына, гүзәл кеше булуга туры юл икәнен аңлату.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- Үз- үзен тәрбияләгән кеше- гүзәл, бәхетле кеше икәнен аңлау.
- Үз- үзеңне тәрбияләү ысулларын өйрәтү.
- Аллаһы Тәгалә үзен үзгәртергә теләмәгән кешенең холкын үзгәртмиячәк икәнен белү.

**Эпиграф:** *”Үз- үзеңне тәрбиялә, уңай якка үзгәртергә*

*тырыш- шуның өстендә көн саен эшлә-*

*җирдәге гүзәл кешеләрнең берсе булырсың ”*

**Дәрес барышы**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Пәйгамбәрәбез Мәхәммәд Мостафа (с.г.в.) тормышыннан бер вакыйганы тыңлагыз, аңа исем кушыгыз. Шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*Аллаһның сүзен дөнья кешеләренә җиткерүче Мөхәммәд пәйгамбәребезнең (с.г.в.)ның иң якын туганы абү Талиб вафат булганнан соң, рәсүлне яклаучысы булмаганга күрә, ул яшәгән Мәккә шәһәрендә дингә өндәү бик авырайгач, пәйгамбәр (с.г.в.) Мәккәгә якын Таиф шәһәренә бару уена төште. Таиф гарәпләре Мәккә гарәпләренә дошман булганлыктан пәйгамбәр аларның үзен канат астларына алуларын, ислам динен кабул итүләрен өмет итә иде. Шунлыктан ул Мәккәне ташлап Таифка китте. Ләкин Таиф гарәпләре пәйгамбәрне бик начар каршы алдылар. Ислам динен кабул итү кайда, аңа начар сүзләр ыргыттылар: «Мәккә халкын аздыруың җитмәгән, инде безне дә аздырмакчы буласыңмы?» диделәр. Шунлыктан пәйгамбәр бик өметсезләнеп Таифтан чыгып китте. Шәһәрдән чыккан чакта малай-шалай вә яшь җилкенчәкләр аның артыннан ташлар бәреп калдылар. Пәйгамбәрнең мөбәрәк үкчәләре җәрәхәтләнде, канады. Шул чакта Аллаһы Тәгалә аның янына Җәбраил фәрештәне җибәргән һәм Таиф халкын юк итәр өчен катлы- катлы итеп ике тау ясап куярга тәкъдим иткән. Ләкин Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) ул надан кешеләрдән үч алырга теләмәгән һәм Җабраил фәрештәгә әйткән: “Юк, киресенчә, мин Аллаһ Мәхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.)ның алар арасыннан бер Аллаһка табынучы (ышанучы) һәм Аңа тиңдәшләр кылмаучылар чыгаруына өметләнәм”.*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Бу хикәядә Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.)нең кайсы сыйфатлары аеручә ачык күрсәтелгән?
- Аның сабырлыгы, дошманнарына начарлык теләмәү.
- Хикәягә нинди исем кушып була? (Сабырлык. Чын кеше.)
- Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Чын, гүзәл кешеләр турында).
- Бүгенге дәреснең төгәл темасы- “Кеше- җирнең гүзәл бизәге”.

- Чыннан да, дөньяда иң танылган 100 кеше турындагы информацияны компьютерга туплап, компьютер аны эшкәрткәннән соң, америка галимен шаккаттыргыч нәтиҗесе килеп чыккан: дөньда иң яхшы, биек танылган кеше- Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) икәне ачыкланган. Галим моңа ышанмыйча экспериментны тагын бер ничә мәртәбә ясап карый, ләкин нәтиҗә үзгәрми: Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.)нән гүзәлрәк кеше дөньда юк һәм булачак та түгел.
- Нәм мөселманнар моңа бер дә аптырамый, чөңки алар Җир шарында иң гүзәл, әдәпле кеше- Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) икәнен яхшы беләләр. Ул дөньда иң күркәм (яхшы) холыклы, әдәпле кеше.

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

**1. “Чын, яхшы кешенең сыйфатларын әйтеп бирә аласызмы?”**
- дигән сорауга җавап табу.

- Җирне бары тик чын булган, гүзәл күңелле кеше бизи икән. Чын, яхшы кешенең сыйфатларын әйтеп бирә аласызмы? /Җаваплар/
- Чын кеше булган кешенең күңелендә диндарлык, мәрхәмәтлелек, башкаларны хөрмәтләү һәм сөю хисләре күренә...

**2. Яшәү мәгънәсе.**

- Сезнеңчә, кеше бу дөньяга ни өчен килә? /җаваплар/
- Хөрмәтле укучылар! “Кеше бу дөньяга ни өчен килә?” дигән сорауга күптөрле җаваплар ишетергә мөмкин. Беренче чиратта иң әһәмиятлесе: үзеңнең кем икәнлегеңне онытма. Кешене хайваннан аерып тора торган сыйфатларны бел, өйрән һәм үзләштер. Үзең өчен мөһим булган кешелеклелек сыйфатларын саклап калуны- дөньяда яшәүнең максаты дип бел.

Кайбер кешеләр хайваннардан да түбән дәрәҗәгә төшәләр. Бүгенге көндә 50 ана бала тапса, аның икесе, өчесе нарасыен калдырып, ташлап китә. Бу аналар тавыклардан да түбән дәрәҗәгә тәгәриләр. Тавык – иң куркак хайваннарның берсе булсада, чебиләре дөньяга килгәч, аларны саклар өчен эткә дә, кирәк булса, кешегә дә ташлана.

Бер сорау килеп туа. Әнә шул кешелекнең гасырлар буена килгән казанышларын кемгә, нинди кешеләр кулына тапшырабыз? Әгәр алар белән файдаланучы кеше түбән әхлаклы, үзен генә яратучы икән, фән-техника өлкәсендәге казанышлар зуррак булган саен, кешелеккә киләчәк бәла-казалар хәтәррәк кенә булачак. Әгәр кешенең күңелендә начарлык икән, ул үз кулындагы барлык мөмкинлекләрне яманлык эшләүгә юнәлтәчәк. Шуның өчен дә кешелек дөньясы бәхетле булыйм, дисә, иң элек камил кеше тәрбияләүне беренче урынга куярга тиеш. Әгәр кешенең күңелендә яхшылык икән, ул булганнары белән генә дә башкаларны да, үзен дә бәхетле итә.

Материаль дөнья күзлегеннән караганда, кеше ул – хайваннар дөньясы вәкиле, тагын гадиләштерсәк, формага салынган ит кисәге. Ә инде рухи дөнья күзлегеннән караганда, ул фәрештәләр төркеменнән. Әмма ул фәрештә дә, хайван да түгел. Әгәр дә кеше материаль дөнья богауларыннан арынып, рухи дөнья ләззәтләрен таный ала икән, ул фәрештәләрдән дә югары күтәрелә ала. Әмма өч көнлек дөнья рәхәтлекләре өчен генә яши икән, ул хайваннан да түбән төшә. Җәмгыять үзен нинди генә исем белән атаса да, әгәр камил кеше тәрбияли алмый икән, ул тынычлыкта, матурлыкта яши алмый. Гүзәл кешеләр арасыннан булсак иде без!
- Минемчә, яшәү мәгънәсе Аллаһы Тәгаләне тануда, Ул кушканча яшәүдә, Аның ризалыгы эчен күп итеп изгелекләр кылуда, гүзәл кеше булуда.

**3. Төркемнәрдә эшләү.**

**1нче бирем** ***Хикәя турында фикерләшү.***

- Хәзер сезгә хикәя тәкъдим итәм. Тыңлагач, аңа да исем кушарсыз.

*Бер олы яштә булган карт оныгы белән елга кырыенда утыргандана, малай:*
*- Син нәрсә турында уйлысың?- дип сорый.*
*- Ике бүре турында.*
*- Нинди бүреләр ул?*
*- Кешенең өчке дөньясында туктамас керәш бара. Ул ак һәм кара бүреләр арасында булган керәш шикелле. Малай бик кызыксынып:*
*- Ә кайсы бүре җиңәчәк?- дип сорагач, бабасы:*
*- Син кайсын туйдырасын- шунсы,- дигән.*
- Хикәягә исем кушыгыз (Ак һәм кара бүреләр).

**2нче бирем** ***"Кеше үзе туйдырган бүресе җиңәчәк"*** -дигән сүзне ничек аңлатасыз?

- Кешенең өчке дөньясында "ак һәм кара бүреләр" арасындагы туктаусыз керәш- нәрсә ул? (Кешенең үзенең "ак" һәм "кара" сыйфатлар арасында булган керәш).
- "Кеше үзе туйдырган бүресе җиңәчәк"- дигән сүзне ничек аңлатасыз?

**3нче бирем** ***"Мин башлыйм, син дәвам ит".***
- Балалар! Мин җөмләне башлыйм, ә сез аны дәвам итәрсез.
- Кара"бүрене" туйдыручы кеше нинди була?
- Кара "бүрене" туйдырыр өчен кеше, нинди булырга тиеш? (Саран, тупас, ялкау, тәртипсез, үзен генә кайгыртучы, ялганчы, кешедән көлүче, үзен зурга куючы..., - дөреслектә, имансыз, динсез) булырга тиеш.
- Ак "бүрене" туйдырыр өчен кеше нинди була?
- Ак "бүрене" туйдырыр өчен кеше ... (михербанлы, тырыш, гадел, матур холыклы, тәмле сүзле, ышанычлы, шәфькатле, тугры сүзле, иле өчен кайгыртучан...- дереслектә, иманлы, дини булырга тиеш).
- Андый кеше булыр өчен үзебезне тәрбияләүдә искиткеч зур хезмәт куярга кирәк икән. Ләкин җирне бары тик чын булган, гүзәл күңелле кеше бизи икән. Иң авыры- үзебездә булган начар, ямьсез сыйфатларны җиңәргә, күңелебездән алып ташларга.

**4нче бирем** ***"Ә сез ничек уйлыйсыз?":***

***"Гүзәл кеше үзенең гөнаһларын истә тота- яхшылыгын ынытa, начар кеше- киресенчә".***
- Ә сез ничек уйлыйсыз? Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз? /Җаваплар/

- Бүген экологик катастрофа турында да, эчүчелек, наркомания, фахишәлек, СПИД турында да күп сөйләнелә. Болар бит барысы да кешелекнең беренче төркем кешеләре булып, хайвани теләкләр артыннан, нәфес артыннан гына куып яшәү нәтиҗәсе.

Билгеле, асылыбыз рухи булса да, без материаль дөньяда яшибез. Ул матераль дөньяда вакытлы гына булса да гомер итәбез икән, аны да өйрәнергә, танып белергә, фәннәрне үзләштерергә, матур итеп яши белергә кирәк. Дөнья нигмәтләре белән дә нигмәтләнәсе булмасак, безне җир йөзенә китерү ник кирәк? Әмма бу дөньяда яшәвебез, аның нигмәтләре белән нигмәтләнүебез ул – нигмәтләрнең колы булу, дигән сүз түгел.

Материаль дөнья тәрбиясе генә бирүче кеше: башкаларның үзләрен нинди дә булса ризыкта, яки эштә чикләвен – газаплану дип кабул итә. Ә бит нәфесеңне җиңү, дөнья ләззәтләреннән үзеңне өстен куя алу – бәхет тугелмени, бу – җиңү түгелмени? Әгәр җәмгыять дөрес һәм матур яшәсен, дисәк, гаиләләр күркәм, матур булсын, дисәк, әлбәттә, рухи һәм әхлакый тәрбия беренче урында булырга тиеш.

**5нче бирем** ***"Дин галимнәренә сүз бирик"***
- Дин галимнәре *һәр кешедә* өч төрле зат сыйфатлары бар дип әйтәләр. *Беренче- хайвани сыйфатлар:* кешеләр еш кына ашау, эчү, ял итү, төрле рәхәтләр турында гына уйлыйлар. Адәмдә *шайтани сыйфатлары* да җитәрлек: ул үпкәли- үпкәләтә, рәнҗетә, урлый,

горурланып- мактанып йөри, алдый, хәттә кайсы берсе кеше үтерүгә барып җитә. Әммә шулук кешедә *ферештәгә хас сыйфатлар* да күренә: ул михербанлы, гадел, тугъры, тырыш, рәхмәтле дә була ала. Кайсы сыйфатлар өстенлек тота икәне бары тик кешедән үзеннән тора. Телисең икән- хайваннарча яшисең, телисең - үз өчеңдә шайтанны аздырасың, ә телисең икән- үзеңдә фәрештәләр сыйфатларын үстерәсең.
- Бер кемгә дә әйтмичә, үзең турында бераз гына уйланып кара: шул затларын кайсы сиңа хуҗа микән /Балалар бераз гына уйланып тырсыннар/.
- Бел шуны- башка кешеләргә анысы би-и-к яхшы, ачык күренә.
- Җирне гүзәллек белән бизәгән кеше- үзендә фәрештәләр сыйфатларын булдырырга тырышкан кеше.

**4. "Явызлыкны кире кайтару"- нәрсә дигән сүз?**
- Нәрсә соң ул явызлык? Кем соң ул – явыз кеше? Җир йөзендә үзен явыз дип санаучы берәр кеше бармы икән? Мөгаен, юктыр. Алай булгач, явызлык та юкмы әллә? Барыбыз да әйбәт булгач, явызлык кайдан килеп чыга? Берәүнең дә явызлыкны җене сөйми. Шулай булгач, ул ничек тормышыбызга килеп керә?! Явызлык ул – ут кебек. Утның көче бар нәрсәне юкка чыгаруга, яндыруга корылган. Явызлык та, ут шикелле үк, куркыныч һәм дәһшәтле. Шулай булса да утның да, явызлыкның да йомшак яклары бар. Әгәр учакка яну өчен нәрсә дә булса өстәп тормасак, ул үзеннән – үзе бетә, юкка чыга. Шуның кебек үк, явызлыкны да әледән-әле котыртып, куәтләп тормасаң, үзеннән-үзе бетә. Чөнки явызлык ул явызлыктан көч ала, куәтләнә.
Явызлыкның үзенчәлеге – ачу килүдә, комсызлыкта, кирелектә, сатлык булуда, монафиклыкта күренә. Әмма аның нигезе, тамыры "мин-минлеккә" барып тоташа. Тәкәбберлек, үзеңне генә ярату, башкалардан өстен кую- менә явызлыкның чыганаклары. Яхшылык белән начарлыкка каршы торып, без аның тамырын корытабыз, нигезенә кадәр янып бетәргә мәҗбүр итәбез.
- Явызлыкны кире кайтару- мөселманнарның фарыз (мәҗбүри) гамалләрнең берсе булып санала. Нәрсә микән ул- явызлыкны кире кайтару? Сине үпкәләткән кешене тагын да катрак үпкәләтү микән? Явызлыкны кире кайтару дигән сүз еш кына гаҗәпләнү уята һәм күп очракта дөрес аңлатылмый. Җәлил Фазлыев хәзрәт бу сүзләрне болай дип аңлата: "Сиңа начарлык эшләсәләр дә, ачуыңны чыгарсалар да, син аңа яхшылык белән җавап бир.

**5. Изге Коръән китабыннан.**
- Аллаһы Тәгалә изге Коръән китабында явызлыкны кире кайтару турында болай дип әйтә:
- ***"Әгәр берәү сиңа начар сүз әйтә, начарлык эшли икән, син аңа, әлбәттә, яхшылык белән җавап кайтар. Тагын сиңа начарлык эшли икән, тагын син аңа яхшылык белән җавап кайтар. Килер бер көн, ул үзенең ялгышын аңлар һәм синең дустың булыр" (Коръән. Фуссыйләт: 34) .***
- ***"Әгәр шулай эшли алмасагыз, әле сезнең иманыгыз зәгыйф, сез әле шайтан вәсвәсәсендә, тизрәк Аллаһка кайтыгыз" (Коръән. Фуссыйләт: 36) .***

- Ни өчен безгә начарлык эшләгән кешегә без яхшылык кылырга тиеш?
- Ни өчен бу эшне бөтен кеше булдыра алмый?
- Нинди генә кешеләр начырлыкка каршы изгелек кылалар? (Сабыр, Аллаһы Тәгаләгә буйсынучы, Аның рәхмәтенә өмет итүче кешеләр).

(Пәйгамбәребез (с.г.в.) Таифка дәгъвәт белән барып, андагы кешеләр тарафыннан рәнҗетелгән булса да, Таиф халкына үч итүдән баш тарту вакыйгасы турында сөйләү).

**6. Синең хәлеңне беркемдә аңламый, ә син кеше хәленә керә беләсеңме?**
- Әмма күп очракта тормышыбыздагы авырлыклар, кыен хәлләр башкаларның кылган эшләре аркасында түгел, безнең тирә-юнебездәгеләрне дөрес аңлый алмавыбыз нәтиҗәсендә килеп

чыга. Әгәр башкаларны аңларга тырышсак, без “явызлыкка-явызлык” дигәннең гаять дәрәҗәдә хата булуын танырбыз.

Һәркайсыбыз башкаларны тикшерергә, гаеп итәргә, хөкем чыгарырга яратабыз. Әмма еш кына онытабыз: башкалардагы усаллык та нәкъ безнеке кадәрдер, артык та түгел, ким дә түгел. Сиңа ямьсез сүз әйткәннәр икән, димәк, моңа сәбәп чыгаргансың. Шулчак без дә тагын да ямьсезрәк сүз әйтсәк? Нәрсәгә ирешәбез? Андый вакытта хөрмәтле, күркәм сүз белән җавап кайтарыйк, моңа хәлебез җитми икән, дәшми калыйк. Тынычлыкка ирешербез, менә бу инде явызлыкны җиңү була. Без эчебездәге явызлыкка тышка чыгарга ирек бирмәдек.

Димәк, явызлыкка яхшылык белән җавап бирү – ул үз эчендәге явызлыкны җиңү. Ә ул – иң бөек җиңү. Шуны эшли алмыйбыз икән, чыгырдан чыгып, бәйдән ычкынып, үзебезнең дөреслекне, әйбәтлекне исбатлау өчен нәтиҗәсезгә вакыт әрәм итәбез икән, үзебез дә явыз дип санаган кешедән аерылмыйбыз.

**7. “Бу кадәр гүзәл холыкны кемнәрдән өйрәндең?”**

- Кайвакыт кемнеңдер озак уйлавы, әкрен хәрәкәт итүе бездә ачу уята, безне чыгырдан чыгара. Ә бит бездән әкрен кеше юк икән, димәк, иң әкрене без булыр идек. Бездән ахмак кешебулмаса, иң ахмагы без булыр идек. Андый кешеләрне күрсәк, ачуыбыз чыкмасын. Тормышта кем күбрәк егыла: чабып баручымы, әллә салмак йөгерүчесеме? Чабып баручы күбрәк егыла, билгеле. Шуның кебек, һәр эшнең хәерле ягы бар. Без аның хәерле ягын күрә, бәяли белергә, начар ягыннан гыйбрәт алып яшәргә тиеш. Мисал. Бер бик күркәм холык иясеннән- Локман Хәкимнән: “Бу кадәр гүзәл холыкны кемнәрдән өйрәндең?” – дип сораганнар. “Начар, ямьсез холыклы кешеләрдән. Берәү дә кешеләргә, яки миңа ошамаган сыйфатны күрсәм, ул сыйфат миндә булса, аны бетерергә тырыштым”, дигән. Менә бу – дөрес яшәү рәвеше, менә бу явызлыкка яхшылык белән җавап бирү.

Бар кыенлыгыбыз шунда: башкаларның безне аңлауларын, хөрмәт итүләрен телибез. Үзебез башкаларны аңларга, яратырга, ихтирам итәргә тиеш дип уйламыйбыз. Без күпме генә тырышсак та, тәрбияләсәк тә, ятып чәчләребезне йолкысак та балан агачы виноград бирмәс. Без аның балан булуы белән килешергә, файдалы якларын өйрәнеп, куллана белергә кирәк. Әгәр бар агач бер төрле, яки бар чәчәк бер төсле булса, матурлык күренер идеме? Гәрчә ул без яраткан чәчәк булса да.

Кеше өчен намус, акыл, әдәп, бер-берңне хөрмәт итү, сабырлык — иң кирәкле сыйфатлар. Алар бер-берсе белән нык бәйләнгәннәр.

**8. «Кешенең биш асылы»**

- XIX гасыр шагыйре Мифтахетдин Акмулланың «Кешенең биш асылы» шигырен укып үтәм.
Кеше өчен иң әүвәл — Намус, дигән,
Намусыңны сатып итмә табыш, дигән.
Байлык өчен илен-көнен саткан кеше
Ике дөнья өчен дә ул явыз, дигән.
Икенче иң кыйммәтлесе — Акыл, дигән,
Акылсызда акыл ягы такыр, дигән.
Акылсызда намус та юк, иман да юк,
Ялганга ант итеп барын сатар, дигән.
Өченче иң кыйммәтлесе — Әдәп, дигән,
Әдәп – көчле мәхәббәткә сәбәп, дигән.
Әдәпсездә бәхет тә юк, тәүфыйк та юк,
Кеше исемен күтәрү дә гаҗәп, дигән.
Дүртенче иң кыйммәтлесе — Күңел, дигән.
Күңеле бозык кеше — кеше түгел, дигән.
Бозыкларга җир өстеннән асты яхшы,
Яшәмә дә, үлеп җиргә күмел, дигән.
Бишенче иң кыйммәтлесе — Сабыр, дигән,

Сабыр кеше зур бәхетләр табар, дигән,
Бер дә юкка ачуланып дөнья бозу
Бер кайгыдан икенчегә салыр, дигән.
- Димәк, шушы күркәм, гүзәл сыйфатларга ия булган кешеләр - җирнең гүзәл бизәкләре.

**9. Үз- үзеңне тәрбияләү буенча үрнәк эш планын төзү.**
- Иң көчле кеше- үзен (үз кимчелекләрен) җиңгән кеше. Үз- үзеңне тәрбияләү буенча эш планын бергәләп төзик.

*Үз- үзеңне тәрбияләү буенча үрнәк эш планы*

- Тормышта зур максат кую (үзеңне тәрбияләү буенча + һөнәр).
- Аңа ирешер өчен кечкенә максатлар кую.
- Үзеңдә тәрбиялисе, үстерәсе килгән сыйфатлар исемлеге.
- Үзеңдә җиңәсе, бөтерәсе килгән сыйфатлар исемлеге.
- Шуларга ирешер өчен тренинг (кайсы гамәлләр кыласы).
- Даими рәвештә үз- үзеңә (характерыңа, кылган эшләреңә, укуда ирешкән нәтиҗәгә) бәя бирү.
- Максатка ирешү белән яңа максат кую.

**10. Безнең киңәшләр.**

*Истән чыгарма*

- Үз- үзеңне уңай якка үзгәрт: Аллаһы Тагәлә үзен үзгәртергә теләмәгән кешенең холкын үзгәртмиячәк.
- Әйткән сүз- аткан ук. Вәгъдә иткәнче- уйла, иткәч- үтә. Әйткән сүздә, вәгъдәдә тор. Югайсә, син ялганче.
- Нәр көнне гүзәл сыйфатларыңны үстер, кимчелекләреңне бөтер.
- Үз кечеңә ышан- син булдырасың.
- Үзеңне күзәт, контрольдә тот. Көн саен нәтиҗә ясა.

**11. Хәдисләр.**
- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (гәләйһи әссәләм) хәдисләрен укып, алар турында үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

- ***Әгәр сине яхшы эшләрең шатландырса һәм бозык эшләрең кайгыга салса, димәк, син мөэмин (чын мөселман) икәнсең.***
- ***«Ислам диненең иң югары күрсәткече нинди кешедә?» — дип сорадылар. Аллаһның илчесе: «Үзенең теле белән дә, куллары белән да башка мөселманнарга зыян китермәүче кешедә», — дип җавап бирде.***
- ***Берниндн нигезсез кешеләр турында яман уйлаудан сакланыгыз, чөнки начар уй – сүзләрнең иң ялганы. Кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, көнләшмәгез, ачуланышмагыз, бер-берегезне ташламагыз, Аллаһының коллары булган хәлдә бер-берегезгә кардәшләр булыгыз!***

- Кайсы хәдис сезнең күңелегезгә якынрак? Ни өчен?
- Ни өчен бүгенге дәрестә нәкъ менә шушы хәдисләр искә алына?
- Бу хәдисләрдә ачыкланган яхшы, гүзәл кешенең сыйфатларын әйтеп бирегез.
(Күркәм кеше, мөэмин, үзенең яхшы эшләренә сөенә, яман эшләре өчен кайгыра. Ул теле белән дә, куллары белән да башка мөселманнарга зыян китерми һәм начар уйлардан, кешеләрнең гаепләрен тикшерүдән ерак тора).

/Җаваплар/

**V. Рефлексия (Йомгаклау).**
- Дәреснең темасын искә төшерегез. (Кеше- җирнең гүзәл бизәге).

- Бу темага карата сезнең өчен яңа булган фикерләрне искә төшерегез. (*Үз- үзен тәрбияләгән кеше- гүзәл, бәхетле кеше).*
- Нинди киңәшләрне кулланырга уйлысыз? (*"Үз- үзеңне тәрбиялә, уңай якка үзгәртергә тырыш- шуның өстендә көн саен эшлә"- җирдә гүзәл кешеләрнең берсе булырсың*).
- Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграф итеп тактага яздык. Җөмләне хор белән кабатлыйк һәм үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчанда онытмыйк.
- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз? (*Аллаһы Тәгалә үзен үзгәртергә теләмәгән кешенең холкын үзгәртмиячәк).*

**VI. Өй эше:**
- Өй эшен вариантлап бирәбез:
1."Үз- үзеңне тәрбияләү өстендә ничек эшләргә?" ,- дигән сорауга җавап әзерләп килергә.
2.Үз- үзләрен тәрбияләүдә уңышка ирешкән кешеләр турында сөйләү (биек шәхесләр, танылган кешеләр: Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.), Локман Хәким һ. б.).